ЯКШӘМБЕ
24 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 19 (6741)
Аерым номеры 20 тиен.

ВАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) нын ТАТАРСТАНӘ ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ТӘҖРИБӘЛӘР БЕЛӘН УРТАКЛАШУНЫ КИҢ РӘВЕШТӘ ОЕШТЫРЫРГА

Бөтенсоюз социалистик ярышы башланганнан бирле безнең промышленность предприятиеләрендә гаять зур производство тәҗрибәсе тупланды. Аерым эшчеләр, тоташ бригадалар, цехлар, завод-фабрикаларның коллективлары ярышта алдынгылык өчен көрәшеп, үз-үзеңне аямыйча хезмәт итүнең гүзәл үрнәкләрен бирәләр. Алар хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм югары сыйфатлы продукция эшләп чыгау өчен барлык көчләрен, средстволарын, резервларын туплыйлар, производствоны яхшыртуга юнәлдерелгән төрле оештыру-техник чаралары үткәрәләр, технологик процессларга җитди үзгәрешләр кертәләр, һәркайда һәм һәрнәрсәгә экономия режимы өчен көрәш алып баралар. Шуның нәтиҗәсендә хезмәт батырлары үсеп чыгалар, алдынгы тәҗрибәләр барлыкка киләләр. Бурыч промышленность эшчеләренең киң массасында хезмәт батырларын киң популярлаштыру—аларның эшендәге алдынгы тәҗрибәләрне уртаклашудан гыйбарәт.

Безнең республика предприятиеләреннән баш инженерлары Корнеев һәм Зафьянцев иптәшләр булган Н-че заводлар ике ай буе Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын үзләрендә саклап киләләр. Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыккан коллективлар бездә аз түгел. Аларның җиңүгә ирешү юлларын өйрәнергә, яхшы тәҗрибәләрен башка пердприятиеләргә дә күчерергә кирәк.

Күптән түгел безнең газетада Н-че заводлардан мастерской начальнигы Абуталипов һәм группа мастеры Бикжанов иптәшләрнең чыгышлары булды. Иптәш Абуталипов производствода минутлар өчен көрәш турында, ә иптәш Бикжанов группаның планны 200 процентка үтәүгә ничек ирешүе турында сөйләделәр. Аларның эш тәҗрибәләре безнең бик күп коллективларга характерлы. Ләкин шул ук вакытта ул тәҗрибәләр белән коралланмаган коллективлар да аз түге әле. Шулай булгач, Абуталипов һәм Бикжанов кебек иптәшләрнең тәҗрибәләрен киң рәвештә популярлаштырырга кирәк,—бу җитди бурычларның берсе.

Алдынгы тәҗрибәләр белән уртаклашуны оештыруның әһәмияте безнең барыбызга да аңлаешлы. Ләкин, кызганычка каршы, бу мәсьәләгә барлык урычнарда да тиешле игътибарны биреп җиткермиләр әле. Тәҗрибәләр белән уртаклашу шәһәрдәге предприятиеләр арасында гына түгел, хәтта бер предприятие эчендәге цехлар, бригадалар арасында да оештырылмый. Мәсәлән, завком председателе урынбасары иптәш Жуков булган Н-че заводның бер цехында (начальнигы иптәш Пимкин) күрше мастерскойлар, группалар, бригадалар бер берсенең ничек эшләве турында да белмиләр. Анда производство киңәшмәләре үткәрелми, стена газеталары чыгарылмый. Шулай булгач, үзеннән үзе ачык: алдынгыларны мактау да, артта калучыларны тәнкыйтьләү дә юк.

Социалистик ярыш принципларыннан берсе—ул тәҗрибәләр белән уртаклашуны киң рәвештә оештыру. Аннан башка ярыш булырга мөмкин дә түгел. Прозиводство киңәшмәләре үткәрү, алдынгы стахановчыларның, мастерларның, инженер техник работникларның чыгышларын оештыру, стена газеталары чыгару—тәҗрибәләр белән уртаклашуның иң яхшы юллары. Бу юлларны кулланып, тәҗрибәләрне киң рәвештә популярлаштырырга, артта калучыларга ярдәм оештырырга кирәк.

Партия, профсоюз оешмаларының һәм производство командирларының бурычы—эшчеләр массасын фронт һәм ил алдындагы бурычларны үтәүгә туплаудан, алдынгы тәҗрибәләрне арттырудан һәм үстерүдән гыйбарәт булырга тиеш.

—◆—

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР САЛЬСКИНЫ ҺӘМ МИКОЯН-ШӘҺӘРНЕ АЛДЫЛАР

22 нче январьда КӨНЬЯК ФРОНТ гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә САЛЬСК шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар.

ЗАКАВКАЗЬЕ ФРОНТЫ гаскәрләре МИКОЯН-ШӘҺӘРНЕ алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР АРМАВИР ШӘҺӘРЕН ҺӘМ РАЙОН ҮЗӘГЕ ВОЛОКОНОВКАНЫ АЛДЫЛАР

1. 23 нче январьда ЗАКАВКАЗЬЕ фронты гаскәрләре, омтылышлы рәвештә һөҗүм итеп, АРМАВИР шәһәрен һәм зур тимерюл үзелын алдылар.

2. ВОРОНЕЖ фронты гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерә барып, район үзәге һәм зур тимер юл станциясе ВОЛОКОНОВКАНЫ алдылар.

9 көнлек операцияләр нәтиҗәсендә Воронеж фронты гаскәрләре дошманның 17 пехота дивизиясен тар-мар иттеләр, шулардан: венгерларның 9 пехота дивизиясе (6, 20, 7, 13, 10, 12, 19, 23 һәм 9 нчы пехота дивизияләре һәм аерым танк бригадасы); немецларның 4 пехота дивизиясе (26, 168, 385 һәм 387 нче пехота дивизияләре), немецларның аерым 5 пехота полкы һәм 60 танктан торган бер аерым танк отряды; итальяннарның 2, 3, 4 нче тау-укчы, 156 нчы пехота дивизияләреннән торган Альп корпусы.

Воронеж янында плен алынган солдат һәм офицерлар саны 22 нче январьда кичкә таба 12.000 кешегә артты. Шулай итеп, Воронеж фронты районында плен алынучы солдат һәм офицерларның гомуми саны 64 меңгә җитте.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

21 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

21 нче январьда Закавказье фронты гаскәрләре каты сугыш нәтиҗәсендә **Ставрополь** шәһәрен, район үзәкләреннән **Тахтаны, Труновскоены, Кугультаны, Старо-Марьевканы** алдылар.

Воронеж фронты гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәге **Синие Липягины**, тимер юл станциясе **Голофеевканы** һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар.

Көньяк—Көнбатыш, Көньяк, Волхов һәм **Ленинград** фронтлары гаскәрләре элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр немец фашистларының чолганып алынган дивизияләрен кыруны дәвам иттерделәр. Шәһәрдән төньяк-көнбатыштарак совет частьлары 1.400 немец солдатын һәм офицерын юк иттеләр. 70 кеше плен алынды 29 орудие, 35 пулемет, 15 миномет, 251 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Шәһәрдә безнең штурм отрядлары гитлерчыларны күп кенә ныгытмалардан бәреп чыгардылар.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга бардылар. Н-че часть сугышчылары дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм чигенүче немецларның артларыннан барып, халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр. Аз гына сугыштан соң гитлерчылар бу пункттан бәреп чыгарылдылар. Сугыш кырында дошманның сафтан чыгарылган 6 танкысы һәм 3 самоход орудиесе калды 45 кеше плен алынды. Икенче бер участокта дошманның ике рота пехотасы тар-мар ителде.

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Немецларның 5 танкысы, 2 орудиесе һәм 200 дән артык автомашинасы юк ителде. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Икенче бер участокта немецлар контратакага 24 танк һәм бер батальон пехота җибәрделәр. Безнең сугышчылар көчле ут белән немецлар пехотасын танклардан аердылар һәм аны кырып ташладылар. Шул ук вакытта артиллеристлар һәм бронебойщиклар дошманның 12 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре элекке юнәлешләрдә һөҗүмне дәвам иттерделәр, ә көчләрнең бер өлеше белән дошманның чолганып алынган частьларының калдыкларын юк итүне дәвам иттерделәр. Үткән тәүлектә совет частьлары халык яши торган күп кенә пунктларны немец басып алучылардан азат иттеләр. Безнең моторлаштырылган һәм танк подразделениеләребез халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта бер батальонга якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр һәм 480 кешене плен алдылар. 16 орудие, 49 пулемет, 14 миномет, 50 автомашина һәм сугыш йөкләре төялгән 100 олау кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары 250 дән артык венгерларны кырдылар һәм халык яши торган бер пунктны алдылар. 6 азык склады, 6 орудие һәм күп сугыш припаслары кулга төшерелде.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар. Иптәш Егоров командалыгындагы танкистлар немецларның сугышчан сафларын изеп ташладылар, халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр һәм немецларның бер пехота полкы штабын тар-мар иттеләр. Икенче бер участокта командиры иптәш Кривошеев булган частьның артиллеристлары дошманның бик күп автомашиналардан торган бер колоннасын күрделәр. Берничә тапкыр ату белән алдагы машиналар җимертелде һәм шосседагы барлык машиналар бер кая да китә алмыйча тыгылып калдылар. Артиллеристлар бик көчле ут ачып дошманның бөтен автомашиналар колоннасын юк иттеләр.

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды берничә уңышлы операция үткәргән. Совет патриотлары 400 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаганнар. Шуның өстенә партизаннар немецларның бер самолетын, бер паровозын, берничә вагонын һәм бер радиостанциясен юк иткәннәр. Орел партизаннарының «Смерть немецким оккупантам» исемле отрядыннан бер группа партизаннар дошманның ике хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. 2 паровоз һәм 34 вагон җимерелгән. Һәлакәт вакытында күп гитлерчылар үлгән һәм яраланган.

Түбәндә Ростов өлкәсенең Скосырская станицасында немец фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Станицадан чигенер алдыннан немецлар гражданнар халкын каң коеп җәзалаганнар Гитлерчы бандитлар урта мәктәпнең 6 нчы класс укучысы Григорий Пашутинны, больница сотрудниги Леонид Перепелкинны, тракторчы Христофор Шиловны, колхоз председателе Егор Харитоновны, инвалид Никанор Лютинны. Александр Широкораденконы, Андрей Шиловны, Александр Семеновны һәм башкаларны атып үтергәннәр Больницада авыру совет гражданнары булган. Фашист ерткычлар аларны елгага куып алып киткәннәр һәм атканнар. Авыруларның бер өлеше урыныннан кузгала алмаган һәм больницада калган Гитлерчылар больницаны анда булган авырулар белән берлектә яндырганнар» Актка кул куйдылар: капитан Митрофанов, капитан Ковтунов, хәрби фельдшер Ткаленко, кече лейтенант Колесников, Скосырская станицасында торучылардан: М Харитонова, М. Воронина, А. Шевченко, С. Воронина һәм Л. Шилова.

СССР Верховный Советы Президиумы Указы

Д. Е. Кочетков, Ю. Е. Максарев, А. А. Морозов һәм Б. Г. Музруков иптәшләргә Социалистик Хезмәт Герое исемә биру турында

Танклар эшләп чыгаруны оештыру, конструкторлык һәм танкларны яхшырту эшендә күренекле хезмәтләре өчен һәм заводларга яхшы җитәкчелек иткән өчен **Социалистик Хезмәт Герое** исемен бирергә һәм бер үк вакытта **Ленин ордены** һәм **«Урак һәм чүкеч» алтын медале** тапшырырга:

1. 76 нчы завод директоры Дмитрий Ермолаевич **Кочетковка.**
2. Коминтерн исемендәге завод директоры Юрий Евгеньевич **Максаревка.**
3. Коминтерн исемендәге заводның баш конструкторы Александр Александрович **Морозовка.**
4. Орджоникидзе исемендәге Уралмашзавод директоры Борис Глебович **Музруковка.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
20 январь, 1943 ел.

—◆—

ТАНК ПРОМЫШЛЕННОСТЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ РАБОТНИКЛАРЫН СССР ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ

Танклар, танк дизельләре һәм бронекорпуслар эшләп чыгаруны арттыру буенча хөкүмәт заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен, СССР Верховный Советы Президиумы указы нигезендә, Танк промышленносте Халык Комиссариаты работникларының зур группасы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

Ленин ордены белән түбәндәге иптәшләр бүләкләнде:

ВКП(б) ның Свердловск Өлкә Комитеты секретаре В. М. Андрианов, завод директоры К. А. Задорожный, СССР Госпланы председателе урынбасары—Танк промышленносте Халык Комиссарынын элекке урынбасары П. М. Зернов, заводның баш конструкторы А. А. Либгарт, ВКП(б) Үзәк Комитеты парторгы М. Л. Медведев, электросварка институты директоры академик Е. О. Патон, ВКП(б) ның Горький Өлкә Комитеты секретаре М. И. Родионов, завод директоры К. К. Яковлев һәм башкалар, барлыгы 45 кеше.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән 133 кеше бүләкләнде;

Кызыл Йолдыз ордены белән 241 кеше;

«Почет билгесе» ордены белән 377 кеше;

«Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән 418 кеше;

«Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән 423 кеше бүләкләнде.

(ТАСС).

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ (Калинин фронты). Н че берләшмәгә Монголия Халык Республикасы делегациясе килде. Делегациягә Кече Хурал Президиумы председателе Бума-Цендә житәкчелек итә. Рәсемдә: Бума-Цендә ату алдынан снарядка имза ясый.

ТАСС фотохроникасы.

ЛЕНИНГРАД БӘЙРӘМ ИТӘ

ЛЕНИНГРАД, (ТАСС). Ленин шәһәренең заводларында һәм фабрикаларында гаять зур күтәренкелек хөкем сөрә. Ленинград блокадасын өзгән Кызыл Армиянең сугыштагы яңа уңышы героик шәһәрдәге эшчеләрнең, инженерларның һәм барлык халыкларның көчләрен ун тапкыр арттырды.

Ленинградлылар Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә үз өсләренә алган йөкләмәләрен яңа баштан карыйлар. Күптән түгел генә токарь Сандор үзенең нормасын киммендә 250 процентка үтәргә сүз биргән иде. Кызыл Армиянең яңа җиңүе хөрмәтенә иптәш Сандор көн саен биш норма бирергә йөкләмә алды һәм токарьлардан комсомолец Иван Маслобоевны ярышка чакырды. Йөзләрчә эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар үз-үзләрен аямыйча Кызыл Армиягә ярдәм итүдә яңа гүзәл үрнәкләр күрсәтәләр.

Предприятиеләрдә Кызыл Армиянең яңа зур җиңүенә багышланган митинглар бара.

Директоры иптәш Цофин булган заводның карт слесаре Федор Иванович Пензан болай диде:

— Безнең шатлыгыбызны әйтеп бетерерлек сүзләр табу кыен. Бөтен илебез көткән һәм әзерләнгән вакыйга тормышка ашырылды. Блокада өзелде! Бөек Сталинга, Кызыл Армиягә, Ленинград һәм Волхов фронтларының барлык сугышчыларына һәм командирларына чын күңелебездән рәхмәт белдерик. Безнең бурыч—Ватанны саклаучыларга ярдәмне тагын да көчәйтүдән, кораллар җитештерүне көннән-көн арттырудан гыйбарәт.

Строгаль участогының начальнигы иптәш Трескин үзенең чыгышында болай диде:

— Иптәш Сталин әйткән сүзләр дөрес булып чыкты. Менә хәзер безнең урамда да бәйрәм! Туган җиребездән немецларны тәмам куып чыгару вакыты ерак түгел инде.

Н-че завод эшчеләренең, инженерларының һәм хезмәткәрләренең митингысында партбюро секретаре иптәш Глотов совет гаскәрләренең яңа җиңүләре турында белдергәннән соң «Кем сөйләргә тели?» дип әйткәч, комсомолка Федорова «Бөтенебез дә телибез!» дип кычкырды. Һәм ул дөрес әйтте Һәркем үзенең тойгыларын әйтергә, Кызыл Армиянең героик сугышчыларына, бөек Сталинга рәхмәт белдерергә теләде. Чыгып сөйләүче барлык иптәшләр:

— Тагын да яхшырак эшләргә! Коралларны тагын да күбрәк бирергә!—дип белдерделәр. Соңыннан алар яңадан станоклар янына бастылар. Продукцияне кабул итүчеләр смена ахырында планнан тыш меңнәрчә әйберләр эшләнгәнлекне исәпкә алдылар.

Ленинградлылар блокада өзелгәннән соңгы беренче көнне беркайчан да онытмаслар. Бөтен шәһәрне зур шатлык чолгап алды. Тантаналы көннәрдәге кебек Ленинград Кызыл флаглар белән бизәлде. Трамвайларда, магазиннарда, ашханәләрдә, урамнарда, йортларда—һәр җирдә—«Блокада өзелде!» дигән темага сөйләүләр барды.

Ленинград бәйрәм итә. Ләкин аның бу шатлыгында тыныч күңеллелекнең күләгәсе дә юк. Һәрвакыттагы кебек йортларның капкалары янында кулларына кызыл тасмалар бәйләнгән дежурныйлар торалар. Всевобуч сугышчылары никлы адымнар белән урамнардан үтеп китәләр, сугыш припаслары тутырылган ящиклар төялгән автомашиналар йөреп торалар.

Һөҗүм дәвам итә. Явыз дошман тәмам тар-мар ителмәгән әле. Фронт шәһәрендә торучылар электәгечә үзләренең сугышчы икәнлекләрен бер минутка да хәтерләреннән чыгармыйлар.

В. И. ЛЕНИННЫҢ МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

Ленин урамында, 5 нче (б) йортта, флигельдә 1888 нче елдан 1889 нчы елга кадәр Ульяновлар семьясы торган.

Хәзер бу йортның түбәнге катындагы бүлмәләрнең берсендә портретлар, күп санлы документлар һәм фотографияләр урнаштырылган. Алар бөтен дөнья пролетариатының даһи юлбашчысы һәм остазы Владимир Ильич Ленинның онытылмаслык образын күз алдына китереп бастыралар.

Советлар Союзы хезмәт ияләре В. И. Ленин музеена зур игътибар бирәләр һәм аны яраталар. Ватан сугышы башланганнан бирле музейдә меңнәрчә кешеләр булып үтте. Анда эшчеләр, хезмәткәрләр, профессорлар, академиклар, укытучылар, укучылар, йорт хозяйкалары, Ватан сугышы геройлары килделәр һәм киләләр. Алар барысы да үзләренең алган тәэсирләрен язып калдыралар. Ленин музее аны караучыларда тирән тәэсир калдыра. Ул бөек көрәшкә һәм дошманны җиңүгә рухландыра һәм чакыра.

Документлар һәм портретлар куелган залда музейны караучылар Владимир Ильич Ленинның Казандагы тормышы һәм эше белән танышалар.

Гимназияне уңышлы тәмам итеп, алтын медаль алганнан соң Ленин 1887 нче елның 13 нче августында Казан университетының юридик факультетына керә.

Озак та үтми Ленин Казанда революционерлар белән элемтә урнаштыра һәм студентларның бер түгәрәгендә катнаша. Студентлар арасында Ленин һәммә яктан да башкалардан аерылып тора. Ул революцион настроениеле, энергияле, күп укыган була һәм үзенең карашларын бөтен көче белән яклый.

1889 нчы елны патша Россиясендәге югары уку йортларының барысында да студентлар чыгышлары башланып китә. 1887 нче елны студентлар чуалышларының көчәюенә «1884 нче елгы университет уставы» дип аталган реакцион уставның тормышка ашырылуы сәбәп була.

Ноябрь ахырында Москвада студентлар чуалышлары башланып китә һәм алар бик тиз арада башка шәһәрләргә дә җәеләләр. 1887 нче елның 4 нче декабрендә чуалышлар Казан университетында да башлана. Ленин студентлар чыгышын хәзерләгән киңәшмәләрдә дә, шулай ук чыгышларның үзләрендә дә иң актив төстә катнаша. Патша жандармериясе шунда ук студентлар өстенә репрессияләр белән ташлана. 5 нче декабрьга каршы төндә Ленин үзенең квартирасында (Комлев урамы, 15 нче йорт, Соловьева йорты) кулга алына.

Аны төрмәгә озата барган пристав Ленинга: «Сез нәрсәгә баш күтәрәсез, егет? Сезнең алдыгызда стена тора бит» ди. Моңа каршы Ленин, «Стенасын стена, ләкин черек, бер төртсәң аварга тора» дип җавап бирә.

Бер вакытны төрмәдә студентлар төрмәдән чыкканнан соң нишләячәкләре турында бер-берләреннән сораша башлаганнар. Ленинга чират килеп җиткәч, аңардан: «Ә син, Ульянов, нәрсә эшләргә уйлыйсың?» дип сораганнар. Ул, минем алда бер генә юл, революцион көрәш юлы гына тора, дип җавап биргән.

5 нче декабрьда Ленин университеттан чыгарыла, ә ике көн үткәч—1887 нче елның 7 нче декабрендә, полициянең яшерен күзәтүе астында, Казан губернасының Кокушкино авылына сөрелә. Сөргендә Ленин бер ел чамасы яши һәм 1888 нче елның сентябрендә аңа Казанга кайтырга рөхсәт итәләр. Шул вакыт Ленин Карл Маркcның «Капитал» ын чын күңел биреп өйрәнергә керешә, Казан марксистларының Н. Е. Федосеев оештырган түгәрәгенә керә.

Патша самодержавиесенә каршы беренче бәрелештә 17 яшьлек Ленин революцион чыныгу ала. Шул вакыттан башлап Ленин үзенең бөтен тормышын самодержавиегә һәм капитализмга каршы көрәш эшенә, хезмәт ияләрен изелүдән һәм эксплоатациядән коткару эшенә бирә.

Музейны караучылар аннан киткәндә бу гаять зур тарихи памятникны—В. И. Ленин музей-йортын оештырган һәм саклап калган өчен большевиклар партиясенә һәм Совет хөкүмәтенә рәхмәт әйтәләр, Ленин эшен дәвам иттерүче, тарихи җиңүләрне оештыручы, халыклар юлбашчысы иптәш Сталинга үзләренең мәхәббәтләрен һәм чын күңелдән бирелгәнлекләрен белдерәләр, фашист ерткычларга карата үзләренең нәфрәтләрен белдерәләр, немец чумасыннан ватаныбызны саклау өчен сугышка барырга һәм актык сулышларына кадәр сугышырга әзер торуларын белдерәләр.

Алар бөтен халыкның газаплануы өчен, балаларыбызны, хатыннарыбызны, картларны үтергән өчен, сугышчыларыбызның каны өчен, культура байлыкларыбызны җимергән өчен үч алырга дип Ленин—Сталин исеме белән ант итәләр.

Иптәш Морозов частеның музейда булган сугышчылары һәм командирлары болай дип язып калдырдылар: «В. И. Ленин музей-йорты бездә зур тәэсир калдырды. Безнең һәрберебезнең күз алдына коммунизм эше өчен бөек көрәш алып барган Ленин образы килеп басты. Алдагы сугышларда, фашист ерткычларга каршы бәрелешләрдә бөек Ленин—Сталин исемнәре безне яңа җиңүләргә рухландыралар».

Бер группа очучылар болай дип язганнар:

«В. И. Ленин музей-йортын караганнан соң без, Н че авиаполк командирларыннан бер группа, үзебезнең ватаныбызга, сөекле юлбашчыбыз Ленинга карата тагын да тирәнрәк мәхәббәт белән китәбез. Озакламый без фронтка очабыз. Безнең һәрберебез Ленин куйган бурыч өчен аяусыз көрәшергә һәм бөек октябрь казанышларына кул сузган немец бандитларны юк итәргә әзер тора. Ленин ватаны азат һәм бәхетле булыр. Политрук Козбетов».

74 нче мәктәп укучылары язмасыннан:

«... Без, 74 нче мәктәп укучылары, Ильич укыган кебек укырга, уяу булырга сүз бирәбез. Кабахәт дошманның хыянәтчел һөҗүменә җавап итеп, без Ленин комсомолы тирәсенә, коммунистлар партиясе тирәсенә, бөек Ленин эшен дәвам иттерүче сөекле атабыз Сталин тирәсенә тагын да тыгызрак тупланырбыз».

Ленин музей-йорты—илебез хезмәт ияләренең мактанычы.

Х. СӘЙФЕТДИНОВА.
музей мөдире.

ЛЕНИН КАЗАНДА

(АРХИВ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА)

Казан тарихы хезмәт ияләренең азатлыгы һәм бәхете өчен, пролетариат диктатурасының тантанасы өчен көрәш эшенә үзләренең тормышларын, бөтен көчләрен һәм белемнәрен биргән кешеләрнең данлыклы исемнәрен саклый.

Большевиклар партиясенә нигез салучы, хезмәт ияләренең юлбашчысы Владимир Ильич Ленин (Ульянов) турындагы истәлекне Казан шәһәре изге итеп саклый. Ленинның яшьлек еллары Казан белән, Казан университеты белән бәйләнгән.

В. И. Ленин 1870 нче елның 22 нче апрелендә Сембер шәһәрендә туды (хәзер Ульяновск шәһәре).

Сембер гимназиясен тәмам иткәннән соң Владимир Ильич Казан университетына студент итеп алуны сорап гариза бирә. Ләкин аны Сембер гимназиясе директоры биргән бик яхшы характеристика аркасында гына алалар. Университет начальниклары Ульяновларның семьясына шикләнеп карыйлар, чөнки бу семьяның бер члены—Владимир Ильичның агасы Александр, революционер булганлыктан, патша хөкүмәте тарафыннан җәзалап үтерелгән иде. Владимир Ильич турында Сембер гимназиясе директоры шушындый характеристика биргән: «Бик талантлы, һәрвакыт тырыш һәм пөхтә булган Ульянов барлык классларда да беренче шәкерт булды һәм үзенең уңышлары, үсеше һәм үз-үзен тотуы ягыннан иң лаеклы дип каралып, алтын медаль белән бүләкләнде».

1887 нче елның 13 (25) нче августында В. И. Ульяновны Казан университетының юридик факультеты студенты итеп алырга рөхсәт бирелгән.

Университетта укый башлавының беренче көннәреннән үк В. И. Ленин революцион студентлар белән аралаша башлый һәм шуның өчен полициянең яшерен күзәтүе астына алына.

Кискен, кыю һәм бик сәләтле булганлыктан Владимир Ильич студентлар арасында зур дәрәҗә казана.

Шулай ук Владимир Ильич Казанда 1887 нче елның ахырында оештырылган революцион укучы яшьләр түгәрәгендә дә актив катнаша. Полиция департаменты директоры бу түгәрәкне «чиктән тыш заралы юнәлештәге түгәрәк» дип атый. Бу түгәрәк 1887 нче елның 5 нче ноябрендә булган революцион студентлар чыгышына карата зур күләмдә әзерлек һәм оештыру эше үткәрә. Бу чыгышта Владимир Ильич актив катнаша.

Аннан соң Владимир Ильич студентларның 1887 нче елның 4 (16) нчы декабрендә булган җыелышына әзерләнүдә дә актив катнаша.

Җыелыш беткәннән соң 100 ләп студент, шул исәптән Владимир Ильич та, протест йөзеннән, үзләренең университетка керү билетларын кайтарып бирәләр.

Владимир Ильичның актив роль уйнаганлыгын университет инспекторы да раслый. Ул болай дип яза:

«Ульяновның семьясы гадәттән тыш хәлләрдә булганлыктан аның студентлар җыелышына булган карашы инспекциягә аны һәртөрле законга каршы һәм хәтта җинаятьле демонстрацияләргә дә тәмам сәләтле дип санарга мөмкинлек бирде».

Студентлар җыелышында актив катнашкан кешеләрне кулга ала башлыйлар. Шулар арасында 1887 нче елның 5 (17) нче декабрена каршы төндә Владимир Ильич та кулга алына Озакламый аны Казаннан Кокушкино авылына полициянең бик каты яшерен күзәтүе астында сөрәләр. Тик 1888 нче елның сентябрендә генә Владимир Ильичка Казанга кайтырга рөхсәт бирелә.

Шул вакытта ук Ленин Федосеев оештырган марксистлар түгәрәгенә керә.

Владимир Ильич тормышындагы бу вакыйгалар ВКП(б) тарихының кыскача курсында ачык әйтелә.

«Ленин 1887 нче елны Казан университетына укырга керде, ләкин озак та үтмәде, студентларның революцион хәрәкәтендә катнашкан өчен кулга алынды һәм университеттан чыгарылды. Ленин Казанда Федосеев тарафыннан оештырылган марксизм түгәрәгенә керде Ленин Самарага күчкәч, аның тирәсенә тиз арада Самара марксистларының беренче түгәрәге оешты. Ленин ул вакытта ук инде үзенең марксизмны белүе белән һәркемне таңга калдыра иде» («ВКП(б) тарихының кыскача курсы», 17 нче бит).

Казанда В. И. Ленинның революцион эше һәм марксизм теориясен системалы рәвештә тирәнтен өйрәнүе башланды. Кешелек дөньясы даһиенын, пролетариат революциясе даһиенын данлыклы юлы шуннан башлана.

«Ленин революция өчен туды. Ул чыннан да революцион шартлаулар даһие һәм революцион җитәкчелекнең иң бөек мастеры иде» (Сталин).

Бөек Ленин җитәкчелегендә Совет власте социалистик төзелешне җәеп җибәрүгә керешә.

Ленинның даһилыгы хезмәт ияләрен граждан сугышы елларында совет халкының эчке һәм тышкы дошманнарына каршы гаять зур көрәшкә рухландырды.

Ленинның сугышчан байрагы астында, Ленинның бөек дусы көрәштәше һәм аның эшен дәвам иттерүче Иосиф Виссарионович Сталин җитәкчелегендә совет халкы, аның героик Кызыл Армиясе, хәзердә дә үзенең азатлыгы өчен, Совет дәүләтенең, Ленин төзегән дәүләтнең бәйсезлеге өчен Германия фашизмына каршы батырларча гаять каты көрәш алып бара.

Бу байрак астында Кызыл Армия һәм совет халкы явыз дошманны тәмам җиңәрләр.

С. КИРСАНОВ,
Татарстан АССР ның Үзәк Дәүләт Архивының өлкән гыйльми сотруднигы.

АЛДЫНГЫЛАРНЫҢ ТӘҖРИБӘЛӘРЕ БЕЛӘН УРТАКЛАШУНЫ КИҢ РӘВЕШТӘ ОЕШТЫРЫРГА

Язгы чәчүне отлично әзерлек белән каршылarбыз

(Шөгер районы „Хезмәт“ колхозы председателе Абдулла иптәш Юнусов белән беседа)

Безнең колхоз үткән елгы авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы тәгәлләде. Дәүләткә ашлык тапшыру, МТС эше өчен натуралата түләү планнарын тулысы белән үтәде. Үзебезнең колхозда ашлык сугу эшләре тәмамлану белән колхозчылар күршедәге «Спартак» колхозына социалистик булышлык оештырырга карар бирделәр. Анда бер сугу машинасы, 17 ат һәм 36 кеше җибәрдек. Алар «Спартак» колхозының 45 гектар арышын суктылар да инде. Хәзер бодай сугалар.

Безнең бурыч язгы кыр эшләренә үрнәк булырлык итеп әзерләнүдән һәм аны чыннан да хәрби темп белән үткәрүгә ирешүдән гыйбарәт. Бу өлкәдә безнең кайбер эшләребез бар инде. Быел без 780 гектарда язгы чәчү үткәрергә тиешбез. Бу мәйданга җитәрлек орлыклар бар. Аларны чистартып, коры урыннарга салып куйдык, кладовщикка саклау өчен расписка белән тапшырдык. Район орлык лабораториясендә тикшергәч орлыкларның сыйфаты яхшы дип табылды. Мәсәлән, бодайның тишелеше 98 процент, солының—93, ясмыкның—91, бор чакның 99 процент. Орлык чистарту эшендә Фатыйма Якупова, Хаят Гәлләмова һәм Сания Хәерова иптәшләр зур тырышлык күрсәттеләр. Алар сортировканы тәүлек буена туктатмый эшләттеләр.

Авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясауны да кызу темп белән алып барабыз. Чәчкечләрнең 3 се дә ремонттан чыкты. 27 сабанның 8 нә, 32 тырманың 15 нә ремонт ясадык. Камытлар, пастромка баулары, валек кебек әйберләрне тиз көннән җитештереп бетерәбез.

Югары уңыш алуда төп шартларның берсе—кышкы агротехника чараларын яхшы итеп үткәрү. Без басуга 350 тонна тирес чыгардык, 30 центнер көл, 16 центнер кош тизәге җыйдык, 50 гектарда кар тоту үткәрдек. Колхозчыларны кыр эшләренә әзерләү буенча һәрбер бригадада агротехника укулары оештырдык. Хатын-кызларны авыл хуҗалыгы инвентарьларында эшләргә өйрәтү өчен тәҗрибәле картларны беркеттек.

Билгеле, язгы чәчүгә әзерлек буенча безнең эшлисе эшләребез күп әле. Бигрәк тә агротехника чараларын үткәрү һәм ремонт эшләрен тизләтәсебез бар. Без моны эшли алабыз һәм эшләрбез. Колхозчылар данлыклы Кызыл Армиябезнең 25 еллык бәйрәмен язгы кыр эшләренә отлично әзерлек белән каршы алу өчен көрәшәләр.

ТЕКНИК КУЛЬТУРАЛАР ЧӘЧҮ МӘЙДАНЫ КИҢӘЙТЕЛӘ

Быел Буденный районы колхозларында техник культуралар чәчү мәйданы шактый киңәйтелә. Күксагыз чәчү планга караганда ике тапкыр артык чәчеләчәк. Быел беренче тапкыр булarak шикәр чөгендере чәчелә. Моның өчен 300 гектар җир әзерләнә.

«Гигант № 1», Молотов һәм Ворошилов исемендәге колхозларда шикәр чөгендәре чәчүне арттыруга аеруча зур игътибар бирелә. Хәзер бу колхозларда бу культуралар өчен билгеләнгән участокларга кертү өчен ашламалар әзерләнә, кар тотыла.

Январь ахырларында район җир бүлеге тәмәке үстерү буенча звено башлыклары өчен семинар үткәрәчәк. Шундый ук семинарлар шикәр чөгендере һәм күксагыз буенча эшләүчеләр өчен дә үткәреләчәк.

Г. Г.

ӘЗЕРЛЕК ЯХШЫ

АРЧА. (Телефон буенча). «Кызыл тау» колхозында язгы чәчүгә әзерлек эшләре яхшы оештырылган. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт күптән тәгәлләнде. Камыт, постромка баулары һәм башка шундый әйберләр һәрберсе җитәрлек итеп төзәтеп куелды. Барлык культуралар буенча да, колхоз чәчүлек орлыкларын чистартып, коры урынга салып куйган. Аларның саклаЛнышы яхшы.

Колхозда агротехника чараларын үткәрү дә уңышлы бара. 217 гектарда кар тотылды, 294 тонна тирес чыгарылды. 35 центнер көл һәм 25 центнер кош тизәге җыелган. Атларның торышы яхшы.

ЧИСТАИ МТМ е ӨЗЕКЛЕКТӘ

ЧИСТАЙ, 23 январь. (Телефон буенча). Чистай МТМ ы 4 нче кварталда трактор моторларына ремонт ясау планын өзде. Шул кварталда ремонтланырга тиешле булган 176 моторның әле дә 104 нә генә ремонт ясалган. Алар да сводка буенча гына. Фактта 53 кенә мотор ремонттан чыккан. Аларның да кайберләренең төзәтеп бетермәгән урыннары бик күп. Ремонтка кителгән моторларны сүтүдә иясезлек хөкем сөрә. Сүтеп алынган частьлар тәртипсез рәвештә төрле җирдә аунап яталар.

Бу МТМ да нормаль эшләргә нәрсә комачаулый соң? Билгеле, начар җитәкчелек итү. МТМ директоры иптәш Дмитриев ремонт эшләрен сугыш вакыты таләп иткәнчә оештырмый, үз эшендә җавапсызлык, гамьсезлек күрсәтә. МТМ да моторларга ремонт ясау өчен кайбер запас частьлар җитешми. Ә алар шул ук вакытта Шуранда тулып ята. Январь ае үтеп бара. МТМ да бу ай өчен график төзелгәне юк. «Язга ерак, ремонтлап бетерергә өлгерербез әле» ди Дмитриев.

Эшчеләр арасында социалистик ярыш оештырылмаган. Политик масса эшләре чиктән тыш начар куелган. Производство киңәшмәләре сирәк була. Нәтиҗәдә эшләп чыгару нормалары үтәлми. Хезмәт дисциплинасы йомшак. Хәтта прогул ясаучылар да бар.

Ш. ШАКИРОВ.

ТӨНЬЯК ФЛОТ. Рәсемдә: Капитан С. И. Труновның 7—8 мең тонна авырлыгындагы дошман транспортын батырган торпедонос экипажы. Сулдан уңга: С. М. Трунов, өлкән сержант Е. Черных, Г. Гортованный һәм радист Р. Галиев.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

22 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

22 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград** районында, **Воронеждан** көньяктарак, **Төньяк Кавказда, Донның** түбәнге агымы, **Төньяк Донец** районында һәм **Ладога** күленнән көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында шәһәрдән көнбатыштарак хәрәкәт итүче Н-че часть дошманны көчле рәвештә ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгарды. Немецлар берничә тапкыр контратака ясадылар, ләкин һәрберендә дә үзләре өчен зур югалтулар белән артка алып ташландылар. Бу сугышта 400 дән артык гитлерчы юк ителде һәм немецларның 7 танкысы сафтан чыгарылды.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Халык яшиң торган бер пункт районына дошман шактый күп пехота көчләре туплап, совет частьларының алга баруын тоткарларга маташкан иде. Безнең танклар, автоматчиклар десантлары белән, немецлар кулындагы пунктларны әйләнеп үттеләр һәм дошманга тылдан атака ясадылар. Өч сәгатьлек сугышта 700 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 100 гә якын пленный алынды. Бик күп трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга бардылар. Бер участокка немецлар яңа көчләр китерделәр һәм аларны сугышка керттеләр. Безнең подразделениеләр дошманның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм бер батальонга якын дошман пехотасын кырып ташладылар. Икенче бер участокта, безнең частьлар алган халык яши торган бер зур пунктта 10 орудие, 4 танк, 2 самоход пушка, автомашиналар өчен запас частьлар склады һәм 2 азык склады кулга төшерелде. Немецларның декабрь аенда гына әле Бельгиядән Совет—Германия фронтына китерелгән 306 нчы пехота дивизиясенең 579 нчы пехота полкыннан пленга алынган солдатлар үз полкларының соңгы сугышларда бөтенләй туздырылганлыгын сөйләделәр. Аларның әйтүенчә, роталарда бары 10—30 кеше генә калган.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре һөҗүм сугышлары алып бардылар, ә көчләрнең бер өлеше дошманның чолганып алынган гаскәрләре тирәсендәге боҗраны тагын да кысты. Немецлар чолганыштан чыгарга маташып карадылар, ләкин үзләре өчен зур югалтулар белән артка алып ташландылар. Безнең частьлар халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че берләшмә 1.500 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын плен алды. Ачыкландырылган саннарга караганда, Острогожск шәһәрендә 1.000 нән артык дошман солдаты һәм офицеры юк ителгән һәм 600 дән артык кеше плен алынган.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер участокта дошман контратакага 10 танк һәм 5 бронемашина ярдәме белән ике рота пехота җибәрде. Н-че часть подразделениеләре гитлерчыларның контратакаларын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә дошманның 6 танкысы һәм барлык бронемашиналары сафтан чыгарылды, ә немецлар пехотасы үз составының яртысыннан күбрәген югалтып чигенде.

* * *

Полесье өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немецларның бер аэродромына һөҗүм ясаган һәм дошманның 18 самолетын, 16 автомашинасын юк иткән. Ике ай эчендә бу отрядның партизаннары немецларның 20 хәрби эшелонын һәлак итүне оештырганнар. 12 паровоз, 200 дән артык вагон һәм ягулык тутырылган 9 цистерна җимерелгән. Шуның өстенә совет патриотлары елга аркылы салынган бер тимер юл күперен һәм шоссе юлларындагы 8 күперне шартлатканнар.

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсенең Михайловка хуторында немец - фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турында төзелгән акт игълан ителә: «Кызыл Армия ударлары астында чигенгәч чакта немецлар Михайловка хуторын таладылар һәм гражданнар халкыннан күп кешеләрне үтерделәр. Гитлерчылар барлык ирләрне җыеп алдылар һәм 70 яшьлек Никита Балабинны, 68 яшьлек Алексей Чернухинны, 41 яшьлек Михаил Щербинаны һәм аның 16 яшьлек улы Александрны, 41 яшьлек Федор Бойченконы, 30 яшьлек Павел Бойченконы. 30 яшьлек Иван Симоновны, 28 яшьлек Петр Чернышевны. 18 яшьлек Иван Дегтяревны һәм башка кешеләрне елга яры буенда атып үтерделәр. Гражданнар халкын җәзалаганнан соң немец солдатлары хутордагы йортларның күпчелеген керосин сибеп яндырдылар». Актка капитан Митрофанов, капитан Ковтунов, өлкән лейтенант Суворов, Михайловка хуторында торучылардан М Угловатов, А. Щербина, П. Бондаренко һәм В. Швецлар кул куйды.

22 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

22 нче январьда **Көньяк фронт** гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә Сальск шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, район үзәкләре Константиновскаяны, Веселыйны, халык яши торган зур пунктлардан Новый Егорлыкны алдылар.

Төньяк Кавказда Закавказье фронты гаскәрләре Микоян-шәһәрне, район үзәге Удобнаяны, халык яши торган зур пунктлардан Донскоены, Зеленчук-Мостовойны алдылар.

Көньяк - Көнбатыш фронт гаскәрләре Станично-Луганское шәһәрен һәм район үзәген, Кондрашевская тимер юл үзелын, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Ново-Айдарны** һәм район үзәге **Евсугны** алдылар.

* * *

21 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар. 6 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм ике ротага якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр, немецларның контратакаларын кире кайтарып, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман бик каты каршылык күрсәтә. Халык яши торган һәрбер пункт һәм һәрбер уңайлы чик янында бик каты сугышлар бара. Бер авыл бер көн эчендә өч тапкыр кулдан-

(Ахыры 4 нче биттә).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

22 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

кулга күчте. Сугышның нәтиҗәсен совет танкистлары хәл иттеләр. Алар, дошманга фланглардан атака ясап, немецларның ут средстволарын бастырдылар һәм аларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Авылга килү юлларында һәм аның урамнарында дошманның 300 дән артык үле гәүдәләре калды. Гитлерчылар сафтан чыгарылган 5 танкларын, күп коралларын һәм сугыш милекләрен ташлап калдырдылар. Пленныйлар алынды.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Совет частьлары, алга барып, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер участокта дошманның бер полкка якын пехотасы һәм танклары, авиация ярдәме белән, 10 га якын контратака ясадылар. Гитлерчыларның барлык контратакалары кире кайтарылды. Сугышларда дошманның 16 танкысы зарарланды һәм яндырылды, аның җанлы көчләре зур югалтуларга дучар ителде. Н-че часть сугышчылары халык яши торган берничә пунктны алдылар һәм өч ротага якын немец пехотасын юк иттеләр. Мылтык һәм пулемет уты белән дошманның өч моторлы 2 самолеты атып төшерелде.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре элекке юнәлешләрдә һөҗүмне дәвам иттерделәр, өч көчләрнең бер өлеше белән дошманның чолганып алынган дивизияләренең калдыкларын юк итү сугышлары алып бардылар. Ольховаткадан төньяк-көнбатыштагы районда безнең гаскәрләр дошман частьларын тар-мар иттеләр, 700 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырдылар, 1.800 солдатны һәм офицерны плен алдылар. Гвардияче кавалеристлар, кинәт удар ясап, дошманның бер аэродромын алдылар, 15 самолет, 150 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар уңышлы сугышлар алып бардылар һәм халык яши торган 9 пунктны алдылар. Дошман гаять күп җанлы көчләрен һәм техникасын югалта. Халык яши торган бер пунктта гына да дошманның 200 гә якын үле гәүдәләре, 6 танкысы, 4 миномеќты һәм башка кораллары калды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр Микоян-шәһәрне һәм халык яши торган дистәләрчә пунктларны алдылар. Халык яши торган бер пункт районында аеруча каты сугышлар булды. Дошман пехотасы, 30 танк ярдәме белән, Н-че часть позицияләренә контратака ясаган иде. Безнең сугышчылар немецларның контратакасын кире кайтардылар һәм аларны зур югалтуларга дучар иттеләр. Берничә йөз гитлерчы кырып ташланды, дошманның 11 танкысы сафтан чыгарылды. Безнең подразделениеләр, чигенүче дошманны куып барып, 12 километр алга киттеләр. Икенче бер участокта Н-че берләшмә сугышчылары дошманның көчле рәвештә ныгытылган ике терәк пунктын алдылар һәм 6 танкысын сафтан чыгардылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде һәм пленнныйлар алынды.

* * *

Минск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды берничә көн буена немецларның җәза экспедициясенә каршы сугышлар алып барган. Карательләрнең, флангылардан удар ясап партизаннарны аударып ташларга һәм җимерергә маташулары барысы да уңышсыз чыккан. Совет патриотлары 200 гә якын гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм карательләрне бер районнан куганнар. Минск партизаннарының икенче бер отряды январь аенда немецларның 6 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 6 паровоз һәм 52 вагон җимерелгән. Шуның өстенә партизаннар немец-фашист басып алучыларның бер нефть базасын яндырганнар.

23 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

23 нче январьда **Закавказье** фронты гаскәрләре, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, **Армавир** шәһәрен, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Развильноены**, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Изобильноены**, район үзәкләре **Советскаяны** һәм **Отрадная**ны алдылар.

Воронеж фронты гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәге һәм зур тимер юл станциясе **Волоконовканы** һәм район үзәге **Буденноены** алдылар.

Көньяк фронт гаскәрләре район үзәге һәм тимер юл станциясе **Целинаны**, **«Гигант»** совхозын, тимер юл станциясе **Трубецкаяны** алдылар.

* * *

23 нче январьда безнең авиациябез дошманның 3 000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырды, 6 артиллерия батареясының утын бастырды, бер сугыш припаслары складын шартлатты, өч ротага якын пехотасын таркатты һәм бер өлешен юк итте.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары халык яши торган бер пунктны алган чакта 7 самолет, он төялгән бер тимер юл эшелоны, 2 паровоз, 15 автомашина, 4 тягач, 2 зенит орудиесе һәм 10 миномет кулга төшерделәр. Икенче бер участокта немецларның бер рота пехотасы һәм 10 танкысы юк ителде. 5 орудие, 150 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне җәелдерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Танк частьлары, дошманны куып барып, 400 дән артык гитлерчыны кырдылар һәм бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Бер участокта безнең гаскәрләр дошманның мотопехотасына һәм танкларына каршы каты сугышлар алып бардылар. Совет сугышчылары немецларның каршылык күрсәтүен бастырдылар, халык яши торган 3 пунктны алдылар һәм немецларның җыелма отрядыннан 300 солдатны плен алдылар. Н-че часть дошманның өч контратакасын кире кайтарды һәм 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташлады.

* * *

Воронеж фронт гаскәрләре уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Безнең танкистлар, пехота десанты белән, немецларны халык яши торган ике пункттан бәреп чыгардылар. 1 орудие, 26 пулемет, 8 миномет, бер радиостанция һәм сугыш милекләре складлары кулга төшерелде. Икенче бер участокта совет частьлары 1.500 ләп автомашина һәм башка төрле күп сугыш милекләре һәм кораллар кулга төшерделәр.

* * *

Закавказье фронты гаскәрләре алга барып, халык яши торган берничә дистә пунктны алдылар. Бер участокта гына да 200 гә якын гитлерчы кырылды, 106 автомашина, 42 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Халык яши торган бер зур пунктка килү юлларында булган сугышларда командиры иптәш Анисимов булган частька каршы дошман контратака ясады. Безнең сугышчылар дошманны чолган алдылар, ике ротага якын немец пехотасын, дошманның 3 танкысын юк иттеләр һәм халык яши торган бер пунктны алдылар.

* * *

Краснодар краенда хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары бер станицада немецлар гарнизонына һөҗүм иткәннәр. Совет патриотлары 32 немец солдатын һәм офицерын үтергәннәр һәм 40 кешене яралаганнар. «Дзержинец» һәм «Овод» отрядларының бер группа партизаннары, засадалардан торып, берничә дистә немец һәм румын солдатларын һәм офицерларын, 3 йөк машинасын һәм 3 җиңел автомобильне юк иткәннәр. 96 баш мөгезле эре терлек кулга төшерелгән. Бу терлекләрне гитлерчылар халыктан талап алган булганнар.

Күптән түгел Сталинградтан көнбатыштарак почта йөртә торган немец самолеты бәреп төшерелде. Декабрь ахырында немец солдатлары язган хатлар өметсезлек белән тулганнар. Солдат Вильһельм Веттрегель болай дип язган: «Сталинград, үлем комвейеры шикелле, безнең полкларны һәм дивизияләрне ашап кына тора». Ефрейтор Август Эндерс үзенең хатынына болай дип язган: «Мин Гитлербродның кабере́ндә булдым. Ул зур каберлеккә күмелгән. Анда 300 дән артык немец солдатлары ята. Сталинград тирәсендә бары тик немец солдатлары гына күмелгән шундый зур каберлекләр һәрбер километрда очрыйлар». Ефрейтор Иозеф Циммах үзенең ата-аналарына болай дип язган: «Сталинград — тоташтан немец солдатлары каберлеге. Шәһәр читендә кабер казучылар казырга һәм үтерелгәннәрне күмәргә өлгерә алмыйлар». Ефрейтор Вилли Шмидт үзенең туганына болай дип язган: «Сталинград «Верден тегермәне»нә караганда күбрәк корбаннар алды инде». (Верден янында немецлар армиясе 337.000 солдатын югалткан иде). Солдат Пауль Больце: «Монда безгә бер генә нәрсә кала—үлем» дип яза.

23 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

23 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград** районында, **Воронеж**дан көньяктарак, **Төньяк Кавказда**, Донның түбәнге агымы районында, **Төньяк Донец** районында һәм **Ладога** күленнән көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Маныч аша кичкән Көньяк фронт гаскәрләре халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Новый Егорлык районында бер батальон немец автоматчиклары тар-мар ителде. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде. Н-че часть сугышчылары дошманга каршы бик каты бәрелештә бер ротадан артык немец пехотасын кырып ташладылар һәм 70 кешене плен алдылар. 3 танк, 2 бронемашина, 6 орудие, шулардан 2 самоход орудие, 15 автомашина һәм бер сугыш припаслары складі кулга төшерелде.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть халык яши торган 5 пунктны алды, 200 дән артык гитлерчыны һәм дошманның 3 танкысын юк итте. Икенче бер участокта дошманның ике батальон пехотасы, танклар ярдәме белән, безнең позицияләргә контратака ясады. Аз гына сугышканнан соң—немецлар, 8 танкларын калдырып, элекке позицияләренә чигенделәр.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм дошманны халык яши торган күп кенә пунктлардан бәреп чыгардылар. Н-че частьның хәрәкәттәге отряды кинәт немецлар кулындагы бер авылга бәреп кереп, 200 дән артык гитлерчыны кырды. 150 дошман солдатын һәм офицерын плен алды. 5 орудие, 18 пулемет, сугыш милекләре һәм ашлык тутырылган складлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр 220 венгерны чолгап алдылар һәм плен алдылар.

* * *

Закавказье фронты гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр һәм халык яши торган дистәләрчә пунктларны алдылар. Халык яши торган бер зур пунктка килү юлларында совет сугышчылары дошманның ике эскадрон кавалериясен юк иттеләр һәм немецларның 3 танкысын сафтан чыгардылар. Н-че часть 100 автомашина, авиабомбалар складі, гранатлар складі, йөк төялгән 73 вагон, ашлык складі кулга төшерелде. Шулай ук гитлерчылар тарафыннан халыктан талап алынган 4.000 баш мөгезле эре терлек сугышып алынды.

* * *

Смоленск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды 3 тимер юл күперен шартлаткан һәм дошманның 2 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз, солдатлар һәм офицерлар төялгән 15 вагон җимерелгән. Икенче бер отрядның партизаннары кинәт дошман гарнизонына һөҗүм иткәннәр. Ике арада башланып киткән сугышта 57 немец юк ителгән. Күп гранаталар һәм патроннар, шулай ук бер азык складі кулга төшерелгән.

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсенең Каргальско-Белянский хуторында немец-фашист кабахәтләр эшләгән коточкыч ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Кызыл Армиянең басымы астында Каргальско-Белянский хуторыннан чигенгән чакта гитлерчылар үзләренә очраган бер кешене тотып алганнар һәм автоматлардан атып үтергәннәр Немец-фашист бандитлар Василий Капустинны, Пантелей Хромовны, Марина Хромованы, Марфа Харченконы, Михаил Гладковны, Евдокия Алексееваны, Григорий Борисенконы, Иван Гладковны, Петр Гладковны, Виктор Филатовны. Александр Родионовны һәм башка колхозчыларны һәм колхозчы хатын-кызларны үтергәннәр. Шуның өстенә гитлерчы палачлар бер группа совет хәрби пленныйларын ерткычларча теткәләп бетергәннәр.

Гаепсез совет кешеләренең каны үч алырга чакыра. Озакламас, Кызыл Армиянең совет җиреннән кабахәт фашист үтерүчеләрне куар көне килеп җитәр Палачлар белеп торсыннар, түгелгән канның һәрбер тамчысы өчен алар тиешле җәзаларын алырлар» Актка гвардия өлкән лейтенанты Муратов, лейтенантлар Гусев һәм Чернышев, авыл советы председателе Иванеевлар кул куйды.

* * *

Афинада Греция патриотлары оккупантлар казармасына бомба ташлаганнар. 20 дән артык итальян солдатлары үтерелгән. Аграфы районында Греция партизаннарының бер отряды итальяннар гарнизонын тар-мар иткән. 150 итальян солдаты һәм офицеры үтерелгән һәм яраланган.

Төньяк Африкадагы хәлгә карата

ПЕЙРУТОННЫҢ АЛЖИР ГЕНЕРАЛ-ГУБЕРНАТОРЫ ИТЕП БИЛГЕЛӘНҮЕ

НЬЮ ЙОРК, 22 январь. (ТАСС). Юнайтед пресс агентлыгы Алжирга губернатор итеп Пейрутон билгеләнгәнлекне хәбәр итә. Ул Төньяк Африкага Аргентинадан килгән. Анда ул Виши «хөкүмәте»нең илчесе иде.

ЛОНДОН, 22 январь (ТАСС). Англиядә чыга торган «Дейли геральд» газетасы, Пейрутонның Алжирга генерал-губернатор итеп билгеләнүе турында язып, Франция җиңелгәнчегә кадәр Пейрутонның Туниска генеральный резедент булып билгеләнлеген искә төшереп үтә. Анда ул Германиягә каршылык күрсәтергә чакыра торган өндәмә игълан иткән булган. Аннан соң ул, үзенең карашларын үзгәртеп, Петэнга буйсыну турында приказ биргән һәм шуның өчен бүләкләнү сыйфатында Виши хөкүмәтенең эчке эшләр министры итеп билгеләнгән. Бу постта торган чагында ул Петэнга һәм Лавальга каршы булган һәртөрле оппозицияне рәхимсез төстә бастырган һәм Төньяк Африкада Гитлер методларын кертүче беренче француз булуы белән мактанган. Берничә ай үткәч ул Лавальга каршы чыккан, аны хыянәтче дип атаган һәм Лавальны урыныннан алу турында Петэнны күндерергә тырышкан. Немецлар моннан канәгатьләнмичә Петэннан Пейрутонны алып ташлауны таләп иткәннәр. Үткән елның апрелендә Пейрутон кинәт отставкага чыккан. Төньяк Африкага союзниклар гаскәрләре төшерелгәннән соң ул Америка хөкүмәтенә үзенең хезмәтләрен тәкъдим иткән. Газета, Пейрутонны билгеләү—эшләргә мөмкин булган начарлыкларның иң начары дип яза.

Рейтер агентлыгының дипломатия күзәтчесе болай дип яза: — Сугышучы Франция даирәләренең фикеренчә, генерал де Голль генерал Жиро белән килешергә омтылган чакта һәм союзниклар аларның очрашуларын җиңеләйтергә тырышкан чакта Пейрутонны Алжирга генерал-губернатор итеп билгеләү—җиңел генә итеп әйткәндә дә—урынсыз.

ГАЗЕТАБЫЗНЫҢ КИЛӘСЕ НОМЕРЫ 26 НЧЫ ЯНВАРЬДА ЧЫГАЧАК.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ЛФ 621 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 163